**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“28” ноябрь 2025 ел.

№ 4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Җилгелде торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында халык җыенының 2025 елның 30 октябрендәге 1нче һәм 2 нче номерлы карарларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә” сүзләре белән алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Җилгелде авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы — Сәмигуллин Л.Ә.